**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен**
**татар әдәбиятыннан олимпиада биремнәренә җаваплар**
**(муниципаль тур, 2017-2018 уку елы) 7 нче сыйныф**

**Башкару вакыты – 180 минут**
**Гомуми балл - 100**

**I. Теоретик биремнәр (35 балл).**

1. Түбәндә тәкъдим ителгән әсәрләрнең жанрын билгеләгез (20 балл):

*Н.Думави "Яшь ана" –**хикәя***
*Һ.Такташ "Мокамай" –**поэма***
*Ш.Камал "Акчарлаклар"* - ***повесть***
*Г.Исхакый "Җан Баевич" –**комедия***
*Г.Тукай "Туган җиремә" –**күңел лирикасы яки шигырь***

2. Әлеге билгеләмәләрдән портрет төшенчәсенә туры килгәнен сайлап алыгыз (8 балл):

*1) әсәрләрдә табигать күренешләренең бирелешен ачыклый торган теоретик төшенчә*
***2) геройның тышкы кыяфәтенең бирелеше***
*3) әсәрдәге автор фикерен сурәтләү*
*4) әсәрдәге вакыйгаларның бара торган урынын сурәтләү*

3. Ш.Камалның "Акчарлаклар" повестенда акчарлаклар образы кайсы теоретик төшенчәгә туры килә (7 балл):

*А) сезонлы эшчеләр*
*Б)* ***Символ***
*В) Пейзаж*

**II. Әдәби иҗатка караган биремнәр (45 балл).**
**III.**

1. Г.Ибраһимовның "Кызыл чәчәкләр" повестенда Солтан язмышы ничек тәмамлана? (5 балл) (***Партизаннар отрядында чехларны җиңеп, авылга кайта, Гайниягә өйләнә...***)
2. Солтан кайсы иптәшләре турында "алар бервакытта да минем күңелемнән чыкмыйлар" дип искә ала? Ни өчен? ***(Шаһбаз белән Гыйлаҗи)*** (10 балл)
3. Г.Ибраһимовның "Кызыл чәчәкләр" повесте мисалында әсәр исеменең сюжет белән бәйләнешен билгеләп карагыз, автор ни өчен нәкъ шушы исемне сайлаган дип уйлыйсыз? (***Кызыл чәчәкләр дигәндә ул биш дусны, аларның яңа җәмгыятьне төзүгә бәйле идеалларын, хыялларын күздә тота, инкыйлаб елларында аларга бәйле көрәш вакыйгаларын сурәтли, яңа тормыш төзүчеләргә бәйле төстә аларны кызыл төс белән атый...***) (15 балл)

4. Ни өчен әсәр бүген дә актуальлеген югалтмаган дип уйлыйсыз? (15 балл) ***(Бу әсәр сыйнфый көрәш вакыйгаларын гына сурәтләп калмый, ә теләсә кайсы чорда да актуальлеген җуймаячак дуслык, аның кадере, балалар тормышы турында сөйли...)***

**IV. Иҗади бирем (20 балл).**

1. Дуслык турында кечкенә генә хикәя языгыз.